**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2015 ел, 24 октябрь

№ 803

г. Казань

Чаллы моношәһәрен үстерү чараларын гамәлгә ашыру буенча эшче төркем төзү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Чаллы моношәһәрен үстерү чараларын гамәлгә ашыру буенча эшче төркем (алга таба – эшче төркем) төзергә.
2. Эшче төркем турындагы нигезләмәне һәм аның составын (карарга теркәләләр) расларга.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\803.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 24 октябрь, 803 нче
карары белән расланды

**Чаллы моношәһәрен үстерү чараларын гамәлгә ашыру буенча эшче төркем турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Чаллы моношәһәрен үстерү чараларын гамәлгә ашыру буенча эшче төркем (алга таба – эшче төркем) Татарстан Республикасы «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегендә яңа инвестицион проектларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү һәм (яки) төзекләндерү чараларын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы чыгымнарын финанслашу турында 2015 елның 25 сентябрендәге 06-22-55 нче килешү (алга таба – Килешү, Чаллы моношәһәре) нигезендә төзелде.

1.2. Эшче төркем үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

1.3. Эшче төркем үзенең эшчәнлеген федераль дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар белән хезмәттәшлектә гамәлгә ашыра.

2. Эшче төркемнең төп бурычы һәм вазыйфалары

2.1. Эшче төркемнең төп бурычы – Чаллы моношәһәренең социаль-икътисадый хәлен яхшыртуга юнәлдерелгән чараларны, шул исәптән Килешү нигезендә Чаллы моношәһәрен үстерү чараларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру.

2.2. Эшче төркем, үзенә йөкләнгән бурычны үтәү максатында, түбәндәге вазыйфаларны башкара:

2.2.1. Чаллы моношәһәренең социаль-икътисадый хәлен яхшырту мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерли һәм аларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә;

2.2.2. Түбәндәгеләрне гамәлгә ашыруда катнаша:

Чаллы моношәһәрен үстерү буенча комплекслы инвестицион планны һәм Чаллы моношәһәренең социаль-икътисадый хәлен яхшыртуга юнәлдерелгән башка чараларны, шул исәптән Килешү нигезендә;

Чаллы моношәһәрендә яңа инвестицион проектларны тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү һәм (яки) төзекләндерү чараларын;

Чаллы моношәһәрендә яңа инвестицион проектларга булышлык күрсәтү чараларын.

## 3. Эшче төркемнең хокуклары

3.1. Эшче төркем үзе компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләргә хокуклы:

3.1.1. Федераль башкарма хакимият органнарыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан эшче төркемгә йөкләнгән вазыйфаларны үтәү өчен кирәк булган материалларны соратып алырга;

3.1.2. Эшче төркем утырышларында катнашу өчен федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар вәкилләрен чакырырга.

## 4. Эшче төркем эшчәнлеген оештыру

4.1. Эшче төркем составына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары, «Моношәһәрләрне үстерү фонды» коммерциячел булмаган оешмасы һәм башка мәнфәгатьле оешмалар вәкилләре кертелә.

4.2. Эшче төркем җитәкчедән, җитәкче урынбасарыннан, эшче төркем секретареннән һәм әгъзаларыннан тора.

Эшче төркем җитәкчесе эшче төркем эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итә, эшче төркем утырышларының көн тәртибен һәм үткәрү вакытын билгели, үз компетенциясе чикләрендә эшче төркем әгъзаларына йөкләмәләр бирә.

4.3. Эшче төркем эшчәнлеген оештыру һәм методик яктан тәэмин итүне эшче төркем секретаре гамәлгә ашыра.

4.4. Эшче төркем утырышлары кимендә квартларга бер тапкыр үткәрелә. Эшче төркем компетенциясенә караган мәсьәләләрне кичектергесез карап тикшерү кирәк булган очракта, шулай ук эшче төркем әгъзасы эшче төркем утырышын үткәрүне сораткан очракта, эшче төркем рәисе эшче төркемнең планнан тыш утырышларын үткәрү турында карар кабул итә.

4.5. Эшче төркем утырышларын рәис үткәрә, ул булмаган очракта яки аның йөкләмәсе буенча – эшче төркем рәисе урынбасары.

4.6. Эшче төркемнең беренче утырышында Килешүне гамәлгә ашыру буенча чаралар планы раслана.

4.7. Эшче төркем утырышлары, аларда әгъзаларының яртыдан күбрәге катнашса, хокуклы санала.

4.8. Эшче төркем карарлары ачык тавыш бирү юлы белән, утырышта катнашкан эшче төркем әгъзаларының күпчелек тавышы нигезендә кабул ителә.

Тавышлар тигез булган очракта, эшче төркем утырышында рәислек итүче тавышы хәлиткеч санала.

4.9. Эшче төркем карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, һәм утырышны үткәргән көннән соң 3 эш көне эчендә аңа эшче төркем рәисе, ул булмаган очракта – эшче төркем рәисе урынбасары кул куя.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 24 октябрь, 803 нче карары белән расланды

**Чаллы моношәһәрен**
**үстерү чараларын гамәлгә ашыру буенча эшче төркем**
**составы**

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары – эшче төркем җитәкчесе |
| Здунов Артем Алексеевич | Татарстан Республикасы икътисад министры – эшче төркем җитәкчесе урынбасары |
| Таркаева Наталья Александровна | Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары – эшче төркем секретаре |

Эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Гайнетдинов Ренат Вагыйз улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгы |
| Галәветдинов Илдар Хәйдәр улы | «АКИБАНК» ачык акционерлык җәмгыяте идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Гладких Оксана Михайловна | «Моношәһәрләрне үстерү фонды» коммерциячел булмаган оешмасының комплекслы проектларны тормышка ашыруны тәэмин итү һәм мониторинглау идарәсе консультанты (килешү буенча) |
| Заворотченко Родион Александрович | «КамаКристаллТехнолоджи» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Зарипов Равил Хаммат улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Кропотова Наталия Анатольевна | Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Мәһдиев Наил Гамбәр улы | Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Пучкин Константин Юрьевич | «Развитие» сәнәгать паркы идарә итүче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча) |
| Сафин Ленар Ринат улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Стеблов Максим Георгиевич | «Мастер» КИП» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Усманов Айдар Нәзир улы | «ТЭМПО» Кама металлургия комбинаты» ябык акционерлык җәмгыяте финанс директоры (килешү буенча) |
| Хәлиуллина Жанна Евгеньевна | «КАМАЗ» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры урынбасары – корпоратив директор (килешү буенча) |
| Фәйзрәхманов Марат Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначалык департаменты директоры |
| Фәйзуллин Ирек Әнвәр улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Шәһиәхмәтов Фәрит Илдус улы | «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча). |